КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 апрель г.Казань № 352

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга этәрү белән идарә итү системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында" 2019 ел, 4 май, 377 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга этәрү белән идарә итү системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында" 2019 ел, 4 май, 377 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 03 август, 643 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламентка түбәндәге эчтәлекле IV бүлек өстәргә:

**«IV. Системада катнашучылар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре»**

4.1. Система администраторы:

4.1.1. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан оешмалар өчен агрегат системасы белән эшләү буенча айга кимендә ике укыту семинары уздыра;

4.1.2. Ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 числосына кадәр Система координаторына кимендә 10 инвестиция урынын тәкъдим итә.

4.2. Система координаторы:

4.2.1. Квартал саен Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары адресына Система администраторы тарафыннан ачыкланган инвестицион юнәлешләрне анализлау нәтиҗәләре буенча производстволарны локальләштерү турында тәкъдимнәр җибәрә;

4.2.2. Җирле үзидарә органнары белән видеоконференцэлемтә режимында эшләү буенча кварталга кимендә бер киңәшмә уздыра;

4.2.3. 3.1.1 һәм 3.1.5 пунктлары нигезендә Системада катнашучылар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре рейтингын (алга таба – рейтинг) формалаштыра);

4.2.4. Хисап елыннан соң килүче елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты адресына рейтинг нәтиҗәләрен җибәрә.

4.3. Рейтинг әлеге Регламентка кушымта нигезендә төзелә.

4.4. Рейтингтагы урыннарны билгеләү максатыннан, Системада катнашучылар ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр, Система координаторына рейтинг күрсәткечләренең үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.»;

Регламентка «Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучылар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге рейтингын төзү методикасы» кушымтасын өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин